# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Гөлек торак пунктында үзара салым кертү турында**

25.11.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Гөлек торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРА:

«Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Гөлек торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 2500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. «Гөлек торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (зират территориясен коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)»;

2. «Гөлек торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (күпер нигезен ремонтлау, вак таш һәм материаллар сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү)».

3.Әлеге карарны Урыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге башлыгы __________ И.С. Аксюкова